РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СЮНДЮКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӨЕНДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422396 с. Сюндюково, ул. Такташа, 15

422396 Сөендек авылы, Такташ урамы, 15

тел. (84373) 5-07-27, факс 5-07-27, e-mail: ssundukovo@mail.ru
ОГРН 1021606557136, ИНН/КПП 1638001663/163801001

**КАРАР**

**12 марта 2020 года** **№ 57-2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 2010 елның 29 октябрендәге 2-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 2010 елның 29 октябрендәге 2-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктындагы «торак төзелеше өчен (бирелгән)» сүзләреннән соң «(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» дигән сүзләрен өстәргә»;

2) 2 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук Федераль законда каралган «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы карарында каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,15%»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмати стендлар аша халыкка җиткерергә, Тәтеш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://tetushi.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге башлыгы Х.А. Измайловка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Сөендек авыл җирлеге**
**башлыгы** **Х.А. Измайлов**